**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл жирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Советская, д.32г, с. Верхнее Стярле, 423314 Азнакаевского муниципального района**
**Тел.факс (8-5592) 42-6-18,**
**VSt..Azn@tatar.ru**

**Совет урамы, 32г, Югары Стәрле авылы, 423314**
**Тел.факс (8-5592) 42-6-18,**
**VSt.Azn@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» ноябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Югары Стәрле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам**:**

1.Югары Стәрле авылы Беренчемай урамы 1 йорттан 62 йортка кадәр, Тынычлык урамы 1йорттан 29 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2020 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

1.1 Югары Стәрле авылы Совет урамы 1 йорттан 64Б йортка кадәр,Октябрь урамы 1 йорттан 56 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2020 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

1.2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 18 ноябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 19 ноябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Югары Стәрле авылы, Совет ур. , 32г йорт, Югары Стәрле авыл мәдәният йорты залы;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2021елда Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, беренче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны икенче төркем

инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Стәрледә юлларны грейдлау ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрледә юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрле авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү ("Җиңү көне»,» Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне»,» Инвалидлар көне", " Яңа ел», бәйрәм чаралары үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Югары Стәрле авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү, спорт инвентарьлары, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу);
- Югары Стәрле авылы зираты территориясендә контейнер мәйданчыгы урнаштыру (киртәләр алу, койма ясау һәм урнаштыру, контейнер сатып алу, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, коймалар урнаштыру);
- Югары Стәрле авылында зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча түләү);
- Югары Стәрле авылында күмелгән урыннарны карап тоту (генератор сатып алу,тоташ гербицид белән химик эшкәртү, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу);
- Югары Стәрле авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне чүп үләннәреннән,корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, агачлар һәм куаклар, чәчәкләр утырту , килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәтләре күрсәтү;
- Югары Стәрле авылында янгын куркынычсызлыгын карап тоту буенча чаралар(ДЕПО бинасын ремонтлау, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча түләү, техника арендалау);
-Югары Стәрле авылы мәдәният йорты өчен сәхнә костюмнары сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 32г, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 57 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Беренчемай ур., 30 , Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Тынычлык ур 16,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Октябрь ур., 39А Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Октябрь ур., 9 адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.С.Сабирҗанова